# КАШЫҢ КАРА

*Татар халык уен җыры*

Карлыгандай кара, ай, күзләрең,
Бөрлегәндәй йөзләрең.
Шикәрләрдән тәмле, ай, балдак татлы
Сөям дигән сүзләрең.

*К у ш ы м т а:*
Алма бакчасының юлы
Тәрәзәләргә туры.
Әллә сиңа бирелдеме
Бөтен дөньяның нуры?!
Кашың кара, буең зифа,
Күзең дә кара синең.
Кара күзеңә карасам,
Йөрәгем яна минем.

Бишмәтеңдә синең, ай, биш төймә,
Нигә төймәләмисең?
Аралар да безнең, ай, ерак түгел,
Нигә килгәләмисең?

*К у ш ы м т а.*